**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ЯХШЫЙ**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам,17 нче йорт.
Тел.885552 3-44-45.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ**
**РАЙОН ГЛАВА**
**ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул.
Новая, дом 17. Тел. 885552 3-44-45.
E-mail vyah.akt@yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«03» ноябрь 2020 ел № 1

Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Югары Яхшый авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Югары Яхшый авыл җирлеге Башлыгы

**Карар бирә:**

1. 2020 елның 14 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Югары Яхшый, Тәкмәк, Түбән Яхшый һәм Табанлы Күл торак пунктларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

- җирлектәге авылларда юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- җирлектәге авылларда урамнарны яктырту җиһазларын карап тоту;

- җирлектәге авылларда зиратларны ремонтлау һәм карап тоту;

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру.

**"ӘЙЕ"** **"ЮК"**

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Югары Яхшый авылы, Җиңү урамы, 59 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Яхшый авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Зиннатуллина Җ. Г.